**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның 09 гыйнвары 1 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишев авыл җирлеге, Габишев ав., Вахитов ур., 46 й. адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:210101:821 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишев авыл җирлеге, Габишево ав., Вахитов ур., 46 й. адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:210101:821 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2023 елның 9 июненә кадәр дип билгеләргә.

4. Әлеге карар бастырылганнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне межанлау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет

телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

Җитәкче А.А. Новиков